ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«01» июль 2021 ел** **№ 461**

**“2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү” муниципаль программасын раслау турында**

«2013-2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 15 июнендәге 1127-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 8 июлендәге 501 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
01.07.2021 ел, № 461
карарына кушымта

**"2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү"**

# МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**Программаның паспорты**
**(авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту, торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү һәм авыл территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру буенча)**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | "2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү" муниципаль программасы |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2021 ел |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1. "Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары.<br>2. "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары.<br>3. "2013-2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары.<br>4. "Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары |
| Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программада катнашучылар | 1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты.<br>2. « Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс - бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе |

| | |
|---|---|
| Программаны башкаручылар | Җирле үзидарә органнары |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | **Программаның төп максаты:**<br>1. Авыл территорияләренең халык санын шәһәрнекенә карата ким дигәндә 1:4 исәбендә саклап калу. Авылларда һәм бистәләрдә яшәүчеләрнең өлеше ил халкының кимендә 25% ын тәшкил итәргә тиеш.<br>Арзан торак яшьләрне авылда калдырырга яки шәһәр халкын авылга җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.<br>2. Авыл территориясен «Ял итү зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү» юнәлеше буенча төзекләндерү<br>**Программаның төп бурычлары:**<br>1. Авыл халкының торак шартларын яхшырту, авыл халкын арзанлы һәм уңайлы торак белән тәэмин итү, авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү юлы белән яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү.<br>2. Авыл халкының санын саклап калу.<br>3. Авыл җирлегендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру.<br>4. Авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерү, шул исәптән авыл территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | Программа бер этапта 2021 елда гамәлгә ашырыла. |
| Программаның максатчан күрсәткечләре | 1. Авыл территорияләрендә авыл халкын арзан һәм уңайлы торак белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру.<br>2. Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен торак төзегәндә файдалануга тапшыру күләме барлыгы 100 кв. м.<br><br>3. Россия Федерациясе халкының гомуми саны буенча Татарстан Республикасы авыл халкының өлешен саклап калу:<br>- кимендә 25,3%, шул исәптән еллар буенча:<br>2021-25,3 процент;<br>2022 – 25,3 процент;<br>2023-25,3 процент;<br>2024-25,3 процент; |

| | |
|---|---|
| | 2025-25,3 процент;<br>авыл территорияләрендә төзекләндерелгән торак биналарның гомуми мәйданы өлешен 50% ка кадәр арттыру<br>еллар буенча:<br>2021-37 процент;<br>2022-40 процент;<br>2023-43 процент;<br>2024-46 процент;<br>2025-50 процент;<br>4. Авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру |
| Программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыру өчен акчалар тиешле финанс елы кысаларында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә бюджет акчаларын алучыга кадәр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.<br>Финанс белән тәэмин итү чыганаклары «Программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәре һәм чыганаклары» дигән 1 нче таблицада китерелде |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1) авыл территориясендә яшәүче 1 гаиләнең гомуми мәйданы 100 кв. метрдан ким булмаган торак шартларын яхшырту.<br>2) Арча муниципаль районы Хәсәншәех авыл җирлегендә баскетбол һәм волейбол өчен универсаль спорт мәйданчыгы төзү.<br>3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Хәсәншәех авыл җирлегендә урам тренажерлары белән универсаль спорт мәйданчыгы төзү |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Программа чараларын тормышка ашыруны Арча муниципаль районы башкарма комитеты контрольдә тота |

1 нче таблица

«Программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәре һәм чыганаклары»

| № | Проектның исеме (торак пунктны күрсәтеп) | Проектның бәясе, сум | | | | | Проектның максаты һәм көтелгән нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | Шул исәптән: | | | | |
| | | | федераль бюджет | Россия Федерациясе субъекты бюджеты | җирле бюджет | бюджеттан тыш чыганаклар | |
| 1 | 2 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | 1 827 000,00 | 1 479 870,00 | 347 130,00 | 0,0 | 783 000,00 | Авыл территориясендә яшәүче 1 гаиләнең гомуми мәйданы 100 кв. метрдан ким булмаган торак шартларын яхшырту |
| 2. | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Апаз авыл җирлеге, Хәсәншәех авылы, Татарстан урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урнашкан баскетбол-волейбол өчен универсаль спорт мәйданчыгы | 3 794 760,00 | 1 620 000,00 | 380 000,00 | 20 000,00 | 1 774 760,00 | авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру |
| 3. | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Апаз авыл җирлеге, Хәсәншәех авылы, Татарстан урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урам тренажерлары белән универсаль спорт мәйданчыгы | 3 040 820,00 | 1 620 000,00 | 380 000,00 | 20 000,00 | 1 020 820,00 | авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру |
| | Барлыгы | 8 662 580,00 | 4 719 870,00 | 1 107 130,00 | 40 000,00 | 3 578 580,00 | |

## 1. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру буенча эшчәнлектә өстенлекләр

Әлеге муниципаль Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы нигезендә эшләнде.

Авыл территорияләрен комплекслы үстерү дип авыл территорияләренең социаль һәм икътисади потенциалын саклап калу максатларында, авыл халкының тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен шартлар булдыруны аңларга кирәк. Авыл территорияләре дип Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2020 елның 5 маендагы 48/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы авыл территорияләре исемлегендә күрсәтелгән авыл территорияләре аңлашыла.

Арча муниципаль районының административ-территориаль структурасы 16 авыл җирлеген һәм 1 шәһәр җирлеген үз эченә ала.

Авыл территорияләрен үстерү өлкәсендәге муниципаль программаның төп бурычы-тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, авыл халкының төзекләндерелгән торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү, заманча, сыйфатлы социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы булу, ял итү зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү.

Авыл торак пунктларын киметү һәм кечерәйтү авыл җирендә зур территорияләрне кешесез калдыруга, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнештән төшеп калуына китерә. Авылда халык санының кимүе киләчәктә территорияләрнең социаль-икътисади үсешен тәэмин итәчәк эшче потенциалны киметә. Шул ук вакытта авыл җирлекләренең социаль һәм инженерлык инфраструктурасының түбән булуы авыл җирлекләреннән халыкның, бигрәк тә яшьләрнең шәһәрләргә күчү факторларының берсе булып тора. Халыкны авыл җирендә калдыруның төп шартларының берсе- торак төзү һәм, гомумән, яшәү шартларын яхшырту.

Шулай итеп, әлеге муниципаль программаны эшләү зарурлыгы авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә эшчәнлекнең төп юнәлешләрен актуальләштерү ихтыяҗы белән билгеләнә.

## 2. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сферасының агымдагы торышын тасвирлау, төп проблемаларны тасвирлау

Авыл территорияләрен комплекслы үстерү проблемасын хәл итү авыл халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуда тотрыклы үсешкә ирешүдә мөһим чара булып тора.

Хәзерге вакытта агросәнәгать комплекслары алдына куелган авыл җирлеген азык-төлек белән тәэмин итү бурычы белән эшче кадрларның

сыйфаты туры килмәве күзәтелә. Бу халыкның авыллардан китүе белән аңлатыла.

Авыл территорияләрен үстерүнең объектив үзенчәлекләрен исәпкә алып, шәһәр территорияләре белән чагыштырганда авылда тормыш дәрәҗәсендә һәм сыйфатында сизелерлек аерма булган әлеге ситуацияне үзгәртү федераль, төбәк һәм җирле дәрәҗәдә дәүләт ярдәме чараларын җәлеп итеп, программа - максатчан ысулны куллану юлы белән генә мөмкин.

### 3. Муниципаль программаның максатлары һәм бурычлары

Муниципаль программаның максатлары:

- авыл халкының тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү;

-авыл халкын арзан һәм уңайлы торак белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

- авыл халкы өчен төзекләндерелгән торак тапшыру (сатып алу) күләмен арттыру;

-авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру.

Әлеге максатларга ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителә:

1) авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарга торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү.

2) авыл җирендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту (авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче яки авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарны торак белән тәэмин итү).

3) авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны комплекслы төзекләндерүне үстерү.

3.1. Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту.

Авыл җирлекләрен бетерү һәм кечерәйтү авыл территорияләренең бушап калуына, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнештән төшеп калуына китерә.

Авылның комплекслы үсешендәге тискәре хәлнең сәбәбенең берсе-авыл җирендә яшәүнең уңайлылыгы түбән булу, бу авыл халкының, бигрәк тә яшьләрнең, читкә китүенә тәэсир итә. Шуңа бәйле рәвештә аграр тармакта эшче ресурслар кими.

Яшәү өчен социаль уңайлыкның төп шартларының берсе- авыл халкын төзекләндерелгән торак белән тәэмин итү.

Программа нигезендә торак төзүгә (сатып алуга), шул исәптән өлешләп төзүдә катнашу юлы белән, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчеп китәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарга социаль түләүләр бирү каралган.

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән бирелә торган социаль түләүләр торак төзүнең (сатып алу) исәп-

хисап бәясенең 70 процентын тәшкил итә. Чараларда катнашучыларның үз (шул исәптән заем) акчалары өлеше торак төзелеше (сатып алу) буенча исәп-хисап бәясенең 30 процентын тәшкил итә.

Авыл җирендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга бәйле проблеманы хәл иткәндә программа ысулын куллануның максатка ярашлы булуы элеккеге программаларны тормышка ашыру нәтиҗәләре белән раслана.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 3 декабрендәге 858 номерлы карары белән расланган «2013 елга кадәр авылны социаль үстерү» федераль максатчан программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 15 июлендәге 598 номерлы карары белән расланган «2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәр чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы.

3.2 "Ял итү зоналары, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары, физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү" юнәлеше буенча авыл территориясен төзекләндерү- спорт мәйданчыгы объекты, 2 данә.

Программада авыл территорияләрен төзекләндерү буенча иҗтимагый әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган вәкаләтләрне үтәгәндә җирле үзидарә органнарына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү карала.

## 4. Муниципаль программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын финанслау федераль, республика һәм Арча муниципаль районының җирле бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тормышка ашырыла.

Муниципаль программа чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән җирле бюджет акчаларының күләме ел саен тиешле финанс елына тәгаенләнә.

«Ял итү зоналары, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм аларны төзекләндерү» юнәлеше буенча җирле бюджеттан финанслау республика һәм федераль бюджетлардан финанслашу шарты белән мөмкин.

Әлеге муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль һәм республика бюджетлары акчаларын бирү ел саен билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы арасында төзелә торган килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль программаның көтелгән нәтиҗәләре

Муниципаль Программа Социаль юнәлешле характерда. Муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру авыл җирлеген комплекслы үстерү өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итәчәк, авыл җирлегендә эшкә яраклы потенциалны ныгытачак һәм уңай нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итәчәк:

- авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче гаиләләр өчен куллануга тапшырыла торган (сатып алынган) торак мәйданын арттыру;
- авыл территориясен төзекләндерү, авылда тормыш сыйфатын яхшырту.

## 6. Муниципаль программаны гәмәлгә ашыру белән идарә итү системасы

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру барышын Арча муниципаль районы башкарма комитеты тикшереп тора.

«Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле тоту буенча программа чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итә, чираттагы финанс елына муниципаль программаны финанслау өчен җирле бюджеттан ассигнованиеләргә бюджет заявкасы әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

Программага төзәтмәләр кертү, шул исәптән аны гамәлгә ашыру вакытын озайту, аңа яңа чаралар кертү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 7. Муниципаль программа чаралары исемлеге

| N | Ярдәмче программа чараларының исеме (ведомство максатчан программасы), төп чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Башлану һәм тәмамлану вакыты. | Көтелгән нәтиҗә (кыскача тасвирлама) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| "2021 елга Арча районында авыл халкын арзан һәм уңайлы торак белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру". | | | | |
| 1 | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | Арча МР башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге | 2021 | Гомуми мәйданы 100кв. метрдан ким булмаган күләмдә авыл территорияләрендә яшәүче кимендә 1 гаиләнең торак шартларын яхшырту. |
| | | | | |
| «Ял итү зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү» юнәлеше буенча авыл территориясен төзекләндерү | | | | |
| 3 | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Апаз авыл җирлеге, Хәсәншәех авылы, Татарстан урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урнашкан баскетбол-волейбол өчен универсаль спорт мәйданчыгы | Арча МР башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге | 2021 | авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру |
| 4 | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Апаз авыл җирлеге, Хәсәншәех авылы, Татарстан урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урам тренажерлары белән универсаль спорт мәйданчыгы | Арча МР башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге | 2021 | авыл җирендә яшәүчеләр өчен спорт зонасы булдыру |

## 8. Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү һәм көтелгән соңгы нәтиҗәләр

8.1. Авыл территориясендә яшәүче 1 гаиләнең 100 кв. метрдан ким булмаган торак шартларын яхшырту.

8.2. «Ял итү зоналары, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары, физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен җайлаштырылган физик культура һәм җайлаштырылган спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү» юнәлеше буенча авыл территориясен төзекләндерү - 2 спорт мәйданчыгы.

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р.Фазыйлов